# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

## Татарстан Республикасының жәмәгать судьялары турында

1 статья. Татарстан Республикасының жәмәгать судьялары

1. Татарстан Республикасының жәмәгать судьялары (мировой судьялар) (алга таба - жәмәгать судьялары) Татарстан Республикасының гомуми юрисдикция судьялары булалар һәм Россия Федерациясенең бердәм суд системасына керәләр. Жәмәгать судьяларының вәкаләтләре, эшчәнлеге тәртибе һәм жәмәгать судьяларының вазыйфаи урыннарын булдыру тәртибе Татарстан Республикасы Конституциясе һәм әлеге Закон белән билгеләнә.

2. Жәмәгать судьяларының суд эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибе федераль закон белән билгеләнә, ә суд эшчәнлегенең административ хокук бозулар турындагы эшләргә кагылышлы өлеше Татарстан Республикасы законнары белән дә билгеләнергә мөмкин.

3. Жәмәгать судьяларының үз көченә кергән карарлары, шулай ук аларның законлы күрсәтмәләре, таләпләре, йөкләмәләре, чакыртулары һәм башка мөрәҗәгатьләре дәүләт хакимиятенең барлык федераль органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары, жирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр, урындагы затлар, башка физик һәм юридик затлар өчен катгый була , һәм алар Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының бөтен территориясендә һичшиксез үтәлергә тиеш.

2 статья. Җәмәгать судьяларының статусын гарантияләү

«Россия Федерациясендә судьялар статусы турында» Россия Федерациясе Законында һәм бүтән федераль законнарда судьялар өчен билгеләнгән бәйсезлек, аларнын кагылгысызлыгы, шулай ук аларны матди тәэмин итү һәм социаль яклау гарантияләре җәмәгать судьяларына һәм аларның гаилә әгъзаларына да кагыла.

3 статья. Җәмәгать судьясының компетенциясе

1. Җәмәгать судьясы беренче баскычта түбәндәгеләрне карый:

1) кылган җинаятьләре өчен ин күбе ике ел ирегеннән мәхрүм итү җәзасы бирелергә мөмкин булган җинаяти эшләрне;

2) суд боерыгы бирү турындагы эшләрне;

3) ир белән хатын арасында балалар хакында бәхәс булмаса, никахны өзү турындагы эшләрне;

4) ир белән хатынның бергә тапкан мал-мөлкәтен бүлешү турындагы эшләрне;

5) баланың атасы (анасы) булуны дәгъвалау, баланың атасын билгеләү, ата-ана хокукларыннан мәхрүм итү, баланы уллыкка (кызлыкка) алу турындагы эшләрдән гайре, гаиләдәге хокукый мөнәсәбәтләрдән килеп чыга торган бүтән эшләрне;

6) гариза бирелгән мизгелдә дәгъва хакы хезмәт өчен түләүнең федераль законда билгеләнгән биш йөз минималь күләменнән артмый торган мөлкәти бәхәсләр буенча эшләрне;

7) эштә кабат торгызылу турындагы эшләрдән гайре, хезмәт мөнәсәбәтләреннән килеп чыга торган эшләрне;

8) җир кишәрлекләреннән, корылмалардан һәм башка күчемсез мөлкәттән файдалану тәртибен билгеләү турындагы эшләрне;

9) Административ хокук бозулар турында Россия Федераниясе кодексы һәм Татарстан Республикасы законнары белән җәмәгать судьясы компетенциясенә кертелгән административ хокук бозулар турындагы эшләрне.

2. Җәмәгать судьясы беренче баскычта үзе кабул иткән һәм үз көченә кергән карарларга карата яңа ачылган шартлар буенча эшләрне карый.

3. Җәмәгать судьясы әлеге Закон белән үз компетенциясенә кертелгән эшләрне шәхсән үзе генә карый.

4 статья. Суд участоклары

1. Җәмәгать судьялары үз эшчәнлекләрен суд участоклары чикләрендә гамәлгә ашыралар.

2. Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының гомуми саны һәм суд участокларының саны Россия Федерациясенең Югары суды белән килештерелгән Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы буенча яисә Татарстан Республикасы белән килештерелгән Россия Федерациясе Югары судының инициативасы буенча федераль закон белән билгеләнә.

3. Суд участоклары һәм җәмәгать судьяларының хезмәт урыннары Татарстан Республикасы законнары белән төзелә һәм бетерелә.

4. Суд участоклары районнарның һәм шәһәрләрнең Татарстан Республикасы административ-территория бүленешен исәпкә алып бер участокта 15 меңнән 30 меңгә кадәр халык саны исәбеннән төзелә. Халык саны 15 меңнән кимрәк булган административ-территория берәмлекләрендә бер суд участогы төзелә.

5. Җәмәгать судьясы компетенциясенә караган эшләр бер үк вакытта бүтән судьяның яисә судның юрисдикциясенә

215



тапшырылмаган булса, суд участогы яисә җәмәгать судьясының хезмәт урыны бетерелә алмый.

6. Җәмәгать судьясы чираттагы ялда булган яисә авыру сәбәпле булмый торган чорда аны Татарстан Республикасындагы Суд департаменты идарәсе башлыгы боерыгы белән берәр участокның җәмәгать судьясы алыштыра.

5 статья. Җәмәгать судьясына куелучы таләпләр

1. Татарстан Республикасының 25 яше тулган, югары юридик белемгә ия, юридик һөнәре буенча кимендә биш ел стажы булган, үзен хурларлык эшләр кылмаган, квалификация имтиханын тапшырып, Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясе рекомендациясен алган гражданы җәмәгать судьясы була ала.

Кимендә биш ел судья булып эшләгән затлар квалификация имтиханын тапшырудан һәм Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясе рекомендациясе бирелүдән азат ителәләр.

2. Җәмәгать судьясы Татарстан Республикасы халык депутаты яисә Татарстан Республикасы халык депутатларының жирле Советы халык депутаты була алмый, жирле үзидарә органнарына сайлана алмый, сәяси фиркаләрдә һәм хәрәкәтләрдә була алмый, эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыра алмый, шулай ук, җәмәгать судьясы булып эшләгәндә, фәнни, мөгаллимлек, әдәби һәм башка иҗат эшчәнлегеннән гайре, түләүле бүтән эшне башкара алмый.

6 статья. Җәмәгать судьялары урынына сайлау тәртибе

1. Җәмәгать судьялары урынына кандидатлар сайлауны Татарстан Республикасындагы Суд департаменты идарәсе гамәлгә ашыра, ул кандидатлардан квалификация имтиханын алуны оештыра һәм

Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясенә бәяләмә өчен материаллар җибәрә.

2. Җәмәгать судьялары Татарстан Республикасы Югары суды Рәисенең Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясе бәяләмәсенә нигезләнгән тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан сайланалар.

7 статья. Җәмәгать судьясының вәкаләтләр чоры

1. Җәмәгать судьясы биш елга билгеләнә.

Җәмәгать судьясы урынын биләгән зат, күрсәтелгән чор узгач, әлеге урынга сайлану өчен үз кандидатурасын кабат тәкъдим итәргә хокуклы.

2. Җәмәгать судьясы урынына кабат һәм киләчәктә тагын билгеләнгәндә ул биш елга сайлана.

8 статья. Җәмәгать судьясы вәкаләтләрен туктату һәм туктатып тору

1. Җәмәгать судьясының вәкаләтләре ул сайланган чор узгач йә «Россия Федерациясендә судьялар статусы турында» Россия Федерациясе Законында билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә туктатыла.

2. Җәмәгать судьясының вәкаләтләре «Россия Федерациясендә судьяларның статусы турында» Россия Федерациясе Законында билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясе карары белән туктатып торылырга мөмкин.

9 статья. Җәмәгать судьясы аппараты

1. Җәмәгать судьясының эшен аның аппараты тәэмин итә.

2. Җәмәгать судьясы аппаратының хезмәткәрләре Татарстан Республикасының дәүләт хезмәткәрләре булалар.

3. Җәмәгать судьясы аппаратының структурасы һәм штат расписаниесе Татарстан Республикасында Суд департаменты идарәсе башлыгы тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан раслана.

10 статья. Җәмәгать судьяларының эшчәнлеген финанслау һәм матди-техник тәэмин итү

1. Җәмәгать судьяларының хезмәт хакын түләү һәм судьялар өчен федераль законнарда каралган социаль түләүләр чыгымнарын финанслау Татарстан Республикасының Суд департаменты идарәсе аша федераль бюджеттан гамәлгә ашырыла.

2. Җәмәгать судьясының хезмәт хакы Россия Федерациясе Югары суды Рәисе хезмәт хакының 60 проценты күләмендә билгеләнә.

3. Татарстан Республикасында җәмәгать судьяларының эшчәнлеген матди-техник тәэмин итү Татарстан Республикасының республика бюджеты исәбеннән финанс чараларын Татарстан Республикасының Суд департаменты идарәсенә бирү юлы белән гамәлгә ашырыла.

4. Җәмәгать судьялары эшчәнлеген финанслау Татарстан Республикасының Республика бюджетында аерым юл белән карала.

5. Җәмәгать судьялары тарафыннан суд эшчәнлеге өчен кирәкле биналар һәм корылмалар Татарстан Республикасының район, шәһәр администрацияләре тарафыннан бирелә.

11 статья. Җәмәгать судьяларының суд утырышлары залында дәүләт хакимияте символлары

1. Җәмәгать судьяларының суд утырышлары залында Татарстан Республикасының Дәүләт флагы куела һәм Татарстан Республикасының Дәүләт гербы сурәте урнаштырыла.

2. Суд эшчәнлеген башкарганда җәмәгать судьясы мантия киеп утыра.

12 статья. Йомгак нигезләмәләр

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән гамәлгә кертелә.

2. Җәмәгать судьялары сайланганга кадәр җәмәгать судьялары компетенциясенә кертелә торган эшләр район (шәһәр) судлары тарафыннан карала, дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1999 елның 17 ноябре
№ 2440